

# Чишмә



## 52 НЧЕ ТАТАР УРТА ГОМУМ БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ

№64




### УКЫТУЧЫ АПАМ

Укытучы апам әйбәт,
Әни кебек кайгырта.
Яхшы кеше булыгыз дип,
Киңәшләр биреп тора.
Укырга да, язарга да,
Санарга да өйрәтә.
Кирәк чакта шелтәли дә,
Тырышсак үсендерә.
Барыбыз да беләбез бит
Тиздән була зур бәйрәм.
Укытучылар көне белән
Котлыйбыз чын күңелдән.

### КОТЛЫЙБЫЗ



Безнең матур мәктәптә
Эшли абый-апалар.
Әйбәт булгангадыр инде,
Безне бик яраталар.
Тиздән Укытучылар көне,
Котлыйбыз һәммәгезне:
Укытучы абыйларны,
Укытучы апаларны.
Тырышырбыз, яхшы укырбыз,
Сөендерербез сезне!

Михайлов Самат, 2 нче б



Матур традиция буенча, без октябрь башында игелекле укытучы һөнәрен сайлаган кешеләргә рәхмәт һәм хөрмәт сүзләре белән мөрәҗәгать итәбез. Минем дә мәктәбебезнең барлык мөгаллимнәрен әлеге бәйрәм белән тәбрик итәсем килә. Укытучы! Кеше бу дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсә дә, уңышлары башында укытучысы тора. Укытучы – җәмгыятьтә иң хөрмәткә лаек кеше, зур тормыш юлына чыгаручы. Хөрмәтле укытучылар! Сезгә һәрвакытта да уңышлар юлдаш булсын. Укучыларыгызның рәхмәтләренә төренеп, аларның ярдәмен тоеп яшәргә насыйп булсын. Атачак таңнарыгыз аяз, туасы көннәрегез кояшлы, сәламәтлегегез нык булсын. Бәйрәм белән сезне!

*Якупова Зәринә, 7 нче а сыйныфы укучысы.*

Кадерле Алия Илфаковна! Яраткан укытучыбыз һәм сыйныф җитәкчебез!



Сезне ихлас күңелдән һөнәри бәйрәмегез – укытучылар көне белән тәбрик итәбез! Сезгә авыр, әмма мактаулы изге хезмәтегездә зур уңышлар, ныклы сәламәтлек, бәхет, бик күп шатлыклар телибез. Алия апабыз, сез безнең белән өченче ел эшлисез. Шушы вакыт эчендә Сез безнең иң яраткан укытучыбызга гына түгел, якын сердәшчебез, киңәшчебез, дустыбызга әйләндегез. Гел шундый чибәр, яшь, акыллы, шаян булып калыгыз.

*7 нче а сыйныфы укучылары.*

Кадерле укытучыларыбыз! Сез балалар өчен яңа дөнья ачасыз, аларга яктылык күрсәтәсез, күп белем бүләк итәсез. Монын өчен алар сезгә рәхмәт дип әйтәләр! Барлык укучыларыгыз: алдагы, бүгенге, киләчәк унышларында сезнен рольнең ни дәрәҗәдә мөһим булуын аңласыннар! Эш сезгә арыганлык китермәсен, зирәк һәм гадел булыгыз, укытучылык талантыгыз тулысынча тормышка ашсын! *Эльвина Загидуллина, 9б сыйныфы.*




Заһидуллина Элвина, 9 нчы б сыйныфы укучысы.

## УФА ШӘҺӘРЕНӘ ЭКСКУРСИЯ

Каникул – балаларның да, укытучыларның да көтеп алган вакыты. Без, укытучылар, укучыларның яллары күңелле узсын өчен, төрле чаралар, экскурсияләр оештырабыз. Көзге каникул вакытында Башкортстан Республикасы башкаласы – Уфа шәһәренә экскурсиядә бардык.

31 нче октябрь иртәсе. Сәгать алтынчы яртыда кузгалып киттек. Музыка тыңлый -тыңлый, күңелле итеп, аралаша-аралаша килеп җиткәнебезне сизми дә калдык. Безне ап-ак карга күмелгән Уфа шәһәре каршы алды. Беренче кар яуган икән! Табигать искиткеч матур!



Экскурсия барышында башкорт халкының борынгы тарихы, йолалары белән таныштык, шәһәр исеменең каян килеп чыгуын белдек. Дуслык монументы, Салават Юлаев һәйкәле янында булдык. Танылган шәхесләр – рәссам М.Нестеров, язучылар С. Аксаков, С. Давлатов, М. Кәрим, җырчы Ф. Шаляпин, биюче Р. Нуриев, хәрби начальниклар А. Суворов, В. Блюхер, В. Чапаевның иҗаты һәм тормышы белән бәйле урыннарны карадык, һәрберсе янында фотосурәтләргә төштек. Кафедагы көндезге аштан соң Уфа шәһәренең геология музеенда булдык. Бу музейда моңа кадәр дә булганым бар иде. Ләкин укучылар белән бергә тагын бер тапкыр экспонатларны карау минем өчен зур шатлык булды. Аннан без планетарийда булдык. Күк җисемнәре, планеталар, йолдызлар турындагы фильм укучыларга бик ошады. «Җиңү паркы» хәтер комплексында хәрби техника күргәзмәсе оештырылган иде. Аннан безне “Ләлә-Тюльпан” мәчете каршы алды. Бу мәчет әллә каян күренеп, үзенә тартып тора. Уфалыларның әйтүе буенча, “Ләлә-Тюльпан” шәһәрнең йөзек кашына әйләнгән.

Шул урында безнең экскурсиябез тәгәлләнде, автобуска утырып, туган шәһәребез – Яр Чаллыга юл тоттык. Балалар Уфа шәһәрен үзләре өчен данлы тарихлы шәһәр буларак ачты. Аларның йөзләре шатлыктан балкыды.

*Алия Корбанова, 52 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*

## Мәктәбебез тормышыннан…

Мәктәбебездә 13 нче ноябрь көнне шәһәребезнең Автозавод районы мәктәпләре арасында Халыкара әдәби «Җәлил укулары» бәйгесе уздырылды. Бәйгедә герой-шагыйрь М.Җәлил шигырьләрен төрле рус,татар, украин телләрендә сөйләделәр. Шулай ук сәхнәдән фронтовик язучыларның әсәрләре, укучыларның үзләре иҗат иткән шигырьләре дә яңгырады. Безнең мәктәптән 10 нчы сыйныф укучысы Нурдинова Аделина, 6 нчы сыйныф укучысы Бадретдинова Рената шәһәр турына уздылар. Аларга иҗади уңышлар телик!



8 нче ноябрь көнне мәктәбебездә 1-4 нче сыйныф кызлары арасында «Татар кызы» бәйгесе уздырылды. Бәйгедә һәр сыйныфтан бер кыз катнашты. Бәйгедә үзләренең сәләтләрен, уңган-булганлыгын, тапкырлыгын, гомумән, татар кызының үрнәген күрсәттеләр. Бәйгедә 2 нче а сыйныфы укучысы Минһаҗева Эльвина җиңеп чыкты.

19 нчы октябрь көнне Халыкара «Татарча диктант» акциясе уздырылды. Диктантта 275 кеше катнашты. Иң өлкәне - 75 яшь, иң кечесе-7 яшь иде. Татарча диктантны яздыруда Чаллы татар драма театры актрисасы Лилия Рафаэль кызы Минһаҗева, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Лилия Гибадуллина, мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе баш белгече Халидә Нурулла кызы Шабалина катнашты. Диктант җылы, дустанә мөнәсәбәттә узды.



52 нче мәктәп каникул чорын-да ял лагеры чараларын ки-тапханәдә йомгаклады. Бүген анда әкиятләр кичәсе булды. Укучылар балачак әкиятләрен искә алдылар. катапханәче апалары Илфания Камил кызы яңа әкиятләр белән дә таныштырды. Укучылар рәхәтләнеп компьютер экраны аша да әкиятләр карадылар. Кичәдә мәктәп администрациясе һәм башлангыч сыйныф укытучы-лары да катнашты.

**Безнең адрес: 423827, Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, 52\36, 52 нче татар гомум белем бирү мәктәбе**

Телефон: (8552) 59-36-88
Факс: (8552) 59-36-90
Эл. почта: sch52_chelny@mail.ru

**Без Вебта: https://edu.tatar.ru/n_chelny/sch52**